**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 18 гыйнвар № 13

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренә стимуллаштыру характерындагы өстәмә акчалата түләүләр турында» 2013 ел, 6 февраль, 77 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 октябрь, 717 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның тексты буенча тиешле килешләрдәге «югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр» сүзләрен тиешле килешләрдәге «педагогик хезмәткәрләр» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру тәртибендә һәм шартларында:

исемендә һәм алга таба текст буенча тиешле килешләрдәге «югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр» сүзләрен тиешле килешләрдәге «педагогик хезмәткәрләр» сүзләренә алмаштырырга;

2 нче пунктта:

икенче абзацка «медицина психологлары» сүзләреннән соң «, укытучылар» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацка «фармацевтика персоналы» сүзләреннән соң «, тәрбиячеләр, музыка җитәкчеләре, хезмәт буенча инструкторлар» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Дәүләт сәламәтлек саклау системасы медицина оешмаларының халыкка туберкулезга каршы ярдәм күрсәтүдә турыдан-туры катнашучы медицина, фармацевтика хезмәткәрләренә һәм югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләргә стимуллаштыру характерындагы айлык акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслар белән тәэмин итү тәртибендә:

исемендә һәм алга таба текст буенча тиешле килешләрдәге «югары һөнәри (медицина булмаган) белемле белгечләрнең аерым вазыйфаларын биләүче хезмәткәрләр» сүзләрен тиешле килешләрдәге «педагогик хезмәткәрләр» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\13.doc